Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Кичүчат авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

01 ноябрь 2019 ел №10

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Кичүчат авыл җирлеге
Кичүчат авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан
файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын
билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Кичүчат авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 17 нчы ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичүчат авыл җирлегенең Кичүчат авылында Р.Фәхретдин, Г.Тукай, Мөхәммәдиев, Елга, К.Маркс, Тау, Чишмә урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2019 елның 17 нчы ноябрендә 14 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичүчат авыл җирлегенең Кичүчат авылында Юлдаш, Нефтяниклар, Яшьлек, Киров, Калинин, Җәлил, 8 нче Март, Гагарин урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Кичүчат авыл җирлегенең Кичүчат авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: су алу скважинасы төзү һәм эттерү җайланмасы белән трактор алу?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Халык җыены этапларын Кичүчат авыл мәдәният йорты бинасында, түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы Әлмәт районы, Кичүчат авылы, Юлдаш урамы, 2А йортында уздырырга.

5. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичүчат авыл җирлегенең Кичүчат авылында сайлау хокукына ия булган авыл халкының исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

6. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичүчат авыл башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Кичүчат авылы, Юлдаш урамы, 2А йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

8. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Кичүчат
авыл җирлеге башлыгы Р.Х. Шәйхетдинов